ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ _______________ КАРАР _______________

с. Верхний Услон

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-46.

534

Җылылык, электр, ягулык һәм су белән тәэмин итүче оешмаларның, җылылык энергиясен кулланучыларның, ремонт-төзелеш һәм транспорт оешмаларының, шулай ук Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының үзара хезмәттәшлеген исәпкә алып, җылылык белән тәэмин итү системаларында авария хәлләрен бетерү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Биналар һәм корылмалар иминлеге турында техник регламент» Федераль законына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 25.12.2023 ел, 653-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 20 октябрендәге 1220 номерлы карары белән расланган җылылык, электр, ягулык һәм су белән тәэмин итүче оешмаларның, җылылык энергиясен кулланучыларның, ремонт-төзелеш һәм транспорт оешмаларының, шулай ук Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының үзара хезмәттәшлеген исәпкә алып, җылылык белән тәэмин итү системаларында авария хәлләрен бетерү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипнең 1.3 пунктындагы 12 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инженерлык-техник тәэмин итү челтәре - бинаны һәм (яисә) корылманы инженер-техник тәэмин итү өчен билгеләнгән электр, газ, җылылык, су белән тәэмин итү һәм су чыгару челтәре, элемтә челтәре һәм башка корылмалар, шулай ук мондый челтәрләр җыелмасы»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе вазифаларын башкаручы М. М. Черменский

Әзерләде һәм бастырды:
А. А. Утюгина